РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ САБИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

САБА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

08.11.2022 № 1126-п

«2021-2025 елларга Татарстан Республикасы
Саба муниципаль районының муниципаль
финанслары белән идарә итү» муниципаль
программасын раслау турында

Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Башкарма комитеты
КАРАР БИРӘ:

1. «2021-2025 елларга Татарстан Республикасы Саба муниципаль районының муниципаль финанслар белән идарә итү» муниципаль программасын раслау турында» Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Башкарма комитетының 2020 елның 21 октябрендәге 1409-п номерлы карары (алга таба - Программа) белән расланган «2021-2025 елларга Татарстан Республикасы Саба муниципаль районының муниципаль финанслар белән идарә итү» муниципаль программасына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Программаның паспорты таблицасында «Программаны финанслау күләме» юлын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"

| | |
|---|---|
| Программаны финанслау күләмнәре | Программаны финанслауның гомуми күләме 2021-2025 елларда Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы бюджеты акчалары исәбеннән 37 627,296 мең сум тәшкил итә, шул исәптән:<br>2021 ел - 8 349,857 мең сум;<br>2022 ел - 9 726,737 мең сум;<br>2023 ел - 6 437,026 мең сум;<br>2024 ел - 6 446,022 мең сум;<br>2025 ел - 6 667,654 мең сум.<br>Программаны финанслау күләмнәре фаразлану характерына ия һәм Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Советының чираттагы финанс елына (чираттагы финанс елына һәм план чорына)Саба муниципаль районы бюджеты турындагы карары нигезендә төгәлләштереләчәк. |

»;

1.2. «Программаны ресурслар белән тәэмин итү» 3 бүлеген түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

**«3. Программаны ресурслар белән тәэмин итү**

Программаны финанслауның гомуми күләме 2021-2025 елларда Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы бюджеты акчалары исәбеннән 37 627,296 мең сум

тәшкил итә, шул исәптән:

2021 ел - 8 349,857 мең сум;

2022 ел - 9 726,737 мең сум;

2023 ел - 6 437,026 мең сум;

2024 ел - 6 446,022 мең сум;

2025 ел - 6 667,654 мең сум.

Программаны финанслау күләмнәре фаразлану характерына ия һәм Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Советының чираттагы финанс елына (чираттагы финанс елына һәм план чорына)Саба муниципаль районы бюджеты турындагы карары нигезендә төгәлләштереләчәк.

1.3. Программаның 1 нче кушымтасын әлеге карарга 1 нче кушымта нигезендә яңа редакциядә бәян итәргә.

2. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасының Хокукый мәгълүматлар турындагы http://pravo.tatarstan.ru рәсми порталында һәм Саба муниципаль районының http://saby.tatarstan.ru рәсми сайтында бастырып чыгарырга.

Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Саба муниципаль районының Финанс-бюджет палатасы рәисе Ш.Ә.Сөнгәтовка йөкләргә.

Саба муниципаль районы
Башкарма комитеты Җитәкчесе М.Р. Ишниязов

Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Башкарма комитеты карарына
1 кушымта

"2021 -2025 елларга Татарстан Республикасы Саба муниципаль районының муниципаль финанслары белән идарә итү" муниципаль программасына
1 кушымта

**2021-2025 ЕЛЛАРГА ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ САБА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ МУНИЦИПАЛЬ ФИНАНСЛАРЫ БЕЛӘН ИДАРӘ ИТҮ "**
**МУНИЦИПАЛЬ ПРОГРАММАСЫНЫҢ ТӨП ЧАРАЛАРЫН ФИНАНСЛАУ**

| Төп чараларның исемнәре | Башкаручылар | Төп чараларны башкару сроклары | Финанс чыганагын күрсәтеп финанслау, мең сум | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | 2021 ел | 2022 ел | 2023 ел | 2024 ел | 2025 ел |
| | | | Саба муниципаль районы бюджеты акчалары | | | | |
| Бюджет системасының озак сроклы баланслылыгын һәм тотрыклылыгын тәэмин итү | Саба муниципаль районының Финанс-бюджет палатасы | 2021 - 2025 ел | 8 349,857 | 9 726,737 | 6 437,026 | 6 446,022 | 6 667,654 |
| **Барлыгы** | | | **8 349,857** | **9 726,737** | **6 437,026** | **6 446,022** | **6 667,654** |
| **Барлыгы** | | | **37 627,296** | | | | |